ГОСУДАРСТВЕННАЯ ЖИЛИЩНАЯ ИНСПЕКЦИЯ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Б.Красная, 15/9, г.Казань, 420111

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫЂ ДЂЊЛЂТ ТОРАК ИНСПЕКЦИЯСЕ
Б.Красная ур. 15/9, Казан шђћђре, 420111

тел/факс. 236-91-44. E-mail: tatgi@tatar.ru, сайт: www.gji.tatarstan.ru

№ 28

**П Р И К А З** **Б О Е Р Ы К**

« 2 » март 2023 ел.

Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясендә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу комиссиясе турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенең норматив хокукый актын Россия Федерациясе законнарына туры китерү максатларында боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенең 2016 елның 12 февралендәге 53 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең хезмәт тәртибенә карата таләпләр үтәлеше һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу комиссиясе турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

6 пунктындагы «б» пунктчасында «Татарстан Республикасы Президентының Коррупциягә каршы сәясәт мәсьәләләре идарәсенең» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисенең Коррупциягә каршы сәясәт мәсьәләләре идарәсе» сүзләренә алмаштырырга;

7 пунктның «а» пунктчасында «Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы турында» 2005 елның 14 октябрендәге 103-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 22.1 статьясы нигезендә» сүзләрен «Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы турында» 2017 елның 27 апрелендәге 24-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 26 статьясы нигезендә» сүзләре белән алмаштырырга;

8 пунктта «Татарстан Республикасы Президентының Коррупциягә каршы сәясәт мәсьәләләре идарәсе тарафыннан» сүзләрен «Татарстан Республикасы Рәисенең Коррупциягә каршы сәясәт мәсьәләләре идарәсе» сүзләре белән алмаштырырга;

14 нче пунктны «б» пунктчасында «ТР ДТИ 2015 елның 20 июлендәге 426 номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2015 елның 3 августында 2824 номеры белән теркәлгән) белән расланган вазыйфалар исемлегенә кертелгән» сүзләрен «ТР ДТИ 2021 елның 21 июлендәге 122 номерлы боерыгы белән расланган вазыйфалар исемлегенә кертелгән» сүзләре белән алмаштырырга;

15.5 пунктта «кызыксынган оешмалар» сүзләреннән соң «, коррупциягә каршы тору өлкәсендә «Посейдон» дәүләт мәгълүмат системасы кулланылырга мөмкин,

шул исәптән гаризалар юллау өчен дә» сүзләрен өстәргә.

2. Юридик бүлек җитәкчесенә әлеге боерыкны, дәүләт теркәвенә алу өчен, Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрергә.

Җитәкче С.А. Крайнов